


АКЫЛ
белән
БӘХЕТ

Акыл белән бәхет

Татар халык әкиятләре



Татарстан китап нәшрияты
1963

С(тат.)2
А46

ЭЧТӘЛЕК

Кызыл әтәч 3
Акыл белән Бәхет 6
Балыкчы улы Катып 10
Төшеңне сөйлисеңме? 19
Патша малае белән хезмәтче малае... 24
Мөгезле патша 30
Бака, тычкан, чабата 34
Этнең башы табакта тормый 37
Алтын алмалар 41
Алтын тәмәке савыты 43

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

СЧАСТЬЕ И РАЗУМ

(на татарском языке)

Төзүчесе *Заһри Мөхәммәтҗанов*
Җәмәгатьчелек тәртибендә *Эдуард Касыймов редакцияләде*

Редакторы *К. Котдусова*

Художнигы *В. Карамышев*

Художество редакторы *Б. Әлменов*

Техник редакторы *С. Сәгыйтова*

Корректорлары *М. А. Бычкова, Х. Г. Мөхәметдинова*

Производствога бирелде 15/VII-1963 ел. Басарга кул куелды 23/IX-1963 ел. Кәгазь форматы 70×90 1/16. Учетн.-изд. табак 2,15. Басма табак 2,75(3,22). Тираж 20 000 экз. Заказ № Щ-951. Бәясе 8 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19, 1963 ел.



КЫЗЫЛ ӘТӘЧ

Бик борын заманда яшәгән, ди, бер көтүче. Бу көтүченең булган, ди, ике малае, тагы ничәдер кызы.

Көннәрнең бер көнендә бу көтүче төш вакытында терлекләрне бер күл янына куып китерә. Терлекләре су эчеп ял иткәндә, бу көтүче дә зур малае белән утыралар төшке ашларын ашарга. Көтүдән бер сыерны тоталар да сөтен савып шул сөт белән ипиләрен ашыйлар. Ашап туйгач, савытларында ашап бетерә алмаган сөтләре кала. Атасы малаена:

— Син терлекләрне кара, ә мин бераз йоклап алыем, — ди дә ятып йоклый.

Малай, атасы йоклап ятканда, аның янында терлекләрне карап утыра. Шулай каранып утырган чагында, йоклап яткан атасы авызыннан бер сары чебен чыга да теге сөтле савыт өстенә куна. Савыт өстенә агач саплы пычак куелган була, чебен шул пычак өстеннән йөреп чыга да әкрен генә якындагы тауга таба очып китә.

Малайга әле 12—13 яшь кенә, бала акылы әле башыннан чыгып та бетмәгән була. Утырган урыныннан сикереп тора да малай:

— Бу чебенне тотып үтерәм мин, — дип, чебенне куа китә.

Чебен моңа тотарга бирми. Шул арада теге тауга очып та җитә, бер кечерәк кенә тишектән тау эченә кереп тә китә. Чебен тишектән кергәч, малай әйтә:

— Җир астында озак тора алмассың, чыгарсың, — ди. — Чыккан вакытта барыбер мин сине тотып үтерәм, — ди.

Шулай дип, тишек янында утырып көтә башлый. Озак көтәргә туры килми, чебен тишектән кире чыга да очып та китә. Малай тагын тота алмый кала. Тагын сикереп тора да чебенне куа китә. Чебен очып килә дә табактагы пычак өстеннән кире йөреп чыга һәм көтүченең авызына керә. Шунда көтүче сикереп тора. Тора да малаена әйтә:

— Улым, бик кызык бер төш күрдем әле, — ди. — Имеш, бер далада, ди, сөт күле, ди. Шул сөт күле аркылы күпер, ди. Күпернең яртысы тимердән, яртысы агачтан, ди. Шул күпер аркылы чыктым да, ди, бик ерак юл баргач, барып кердем бер сарайга, ди. Ул сарайда мичкәләргә тутырылган алтын-көмеш! Исәбе-хисабы да юк, ди. Мин, ди, сорадым: бу хәтле мал кемнеке, дип. Миңа әйттеләр: «Кем дә кем кып-кызыл әтәчне сукага җигеп шул тауны сукаласа, мондагы хәзинә шуңа була», дип, — ди.

Малай атасының төш сөйләгәнен тыңлап тора да, эченнән генә: «Мин ул урынны беләм», ди, ә атасына әйтә:

— Хәерлегә булсын инде, — ди.

Кичен өйләренә кайткач, атасыннан биш сум акча сорап ала да малай авылга кызыл әтәч эзләргә чыга. Озак кына эзләгәннән соң, берсенең йортында күрә кып-кызыл бер әтәч. Шуннан бу малай боларга кереп:

— Әтәчегезне миңа сатыгыз, — ди.

Сатылырга булмаган әйбернең хакы күп була, диләр бит. Болар да әтәчләрен сатарга уйламаганга күрә:

— Бик кирәк булгач, әтәчне сатарбыз сатуын, ләкин хакы бер сум, — диләр.

Бу сатулашып тормый, бер сум түли дә кызыл әтәчне тотып алып китә. Өенә кайткач, юкә агач алып, кызыл әтәчне җигәргә сука ясый башлый.

Атасы-анасы «малаебыз акылдан язган», дип өшкертә-төкертә башлыйлар. Малай бер нәрсәгә дә карамыйча үз эшен генә белә. Ике көндә кызыл әтәчкә сука, камыт, тагы башка кирәк-яракларын ясап бетерә. Өченче көнне малай әтәчне җигә

торган сукасын сумкага салып, кызыл әтәчне култык астына кыстырып, энесен ияртеп, теге тау янына китә.

Тау янына барып җиткәч, кызыл әтәчне сукага җигә дә, кызыл әтәч очып китмәсен дип, аны энесенә тоттыра, үзе сукaны тота. Шулай итеп тауны кызыл әтәч белән сукалый башлый. Шул вакыт тау эченнән:

— Сиңа ни кирәк? — дигән тавыш килә.

— Андагы малны бүген төнлә минем өемә илтегез, менә шул кирәк, — ди.

Таудан тагы:

— Ярар, илтербез, сукалавыңны гына туктат, — диләр.

Шул вакыт малай сукалавыннан туктый да, өйләренә кайтып китәләр болар. Иртә торып карасалар, күзләре белән ни күрсеннәр, идән асларында да, бәрәңге базларында да, мичкә-мичкә алтын-көмеш, ди. Шулай итеп, болар бик зур бай булалар хәзер.

Аталары бу ике малайны укыта, ә кызларын кияүгә бирә. Малайларны да өйләндерә. Шулай итеп, бик әйбәт кенә яшиләр болар.

Әмма көтүче аталары иске киемнәре белән чыбыркыны зур сарайларының башына, чардакка менгереп асып куя. Малайлары борыннарын күтәрә башласалар, илтеп шул киемнәр белән чыбыркыны гына күрсәтә икән бу.

— Күп борыныгызны күтәрмәгез, менә шул әйберләрне онытмагыз, — ди икән. Шунда менә әкият бетә. Сезгә рәхмәт тыңлаган өчен, миңа рәхмәт сөйләгән өчен, йокларга вакыт, йоклагыз!



АКЫЛ БЕЛӘН БӘХЕТ

Әүвәл заманда бәхет тә, акыл да кеше күзенә күренеп йөргәннәр, ди. Менә шул заманда бервакыт Акыл белән Бәхет очрашканнар, ди. Очрашканнар да бәхәсләшә башлаганнар, ди.

Акыл әйтә:

— Кеше миннән башка тора алмый, — ди. — Мин булганда бәхет кирәкми, — ди.

Бәхет әйтә:

— Юк, мин булмасам, син бер ни итә алмыйсың. Кеше акылсыз да яши ала дөньяда, — ди.

Болар шулай бәхәсләшеп торганда күрәләр: юл буенда бер егет үгезләр белән сабан сөрә. Акыл әйтә:

— Син миннән көчле булсаң, мин чыгам бу кешенең башыннан, син теләсәң ни эшлә аның белә, — ди.

Шулай диюгә Акыл егетнең башыннан чыгып та китә. Егет акылсыз кала. Малай ташлый сабанын да, үгезләрен дә. Ерак та түгел бер елга агып ята. Килә дә утыра бу су эченә. Утыра да тотына чопыр-чапыр чапылдатырга. Шул вакытта якындагы бер юлдан кәрван үтә. Сәүдәгәрләр сәүдә итеп кай-

тып баралар. Бу сәүдәгәрләр бу суда атларына су эчерә торган булалар. Килеп карасалар, елгада балчыклы су ага.

— Бу ни булыр бу? Нәрсә булган бу елгага? — диләр. Эзләп китәләр су буйлап югарыга таба. Барып карасалар, су эчендә бер егет утыра. Киемнәрен дә салмаган, җиңнәре белән суны болгатып ята. Сәүдәгәрләргә бу сүз сөйләргә дә ирек бирми.

— Кая барасыз, кемнәр сез? — ди.

— Без фәлән-фәлән сәүдәгәрләр, фәлән патшабыз янына барабыз, — диләр.

— О, алай булса, ул минем иң якын дусым иде, — ди, — мәгез бер бүләк үзенә, — ди.

Малай шулай дип судан бер таш тартып чыгара. Бәхет аны шундук гәүһәр ташка әйләндерә. Малай ташны тегеләргә бирә. Сәүдәгәрләр, шундый зур гәүһәр ташын күргәч, куркышалар.

— Ярар, бирербез, — диләр.

Ташны алып китәләр болар. Малай суда утырып кала. Теге сәүдәгәрләр, кайта торгач, патша сараена кайтып җитәләр. Керәләр туп-туры патша янына. Патшага ташны бирәләр.

— Мә, падиша, сезнең шундый-шундый җирдә яшәгән дустыгыз җибәрде, — диләр.

Патша гәүһәр ташны кулына ала да уйлый: кем икән ул якын дус? — ди.

— Кем ул, исемен сорамадыгызмы? — ди тегеләргә.

— Юк, белмибез, — диләр.

— Алайса, барып үзен алып килегез, — ди патша.

Бер сәүдәгәр борыла да чыгып китә. Бара теге су буена. Барып җитсә, егет утыра үз урынында, су эчендә.

— Әйдә, патша чакыра сине, — ди сәүдәгәр.

— Һәй, җүләр, — ди егет, — минем падишаны гомеремдә дә күргәнем юк, бармыйм, — ди.

Сәүдәгәр ни әйтсә дә, бу бармыйм дип кенә тора. Яхшы да сөйли, яман да сөйли сәүдәгәр, бу, бармыйм, ди.

— Җүләр, — ди сәүдәгәр, — син шундый бүләк бирдең падишага, әйдә барыйк, — ди.

Зак. Ш-951 — 3

— Юк сүзне чын булса да сөйләмә, мин сине дә, падишаһны да күргәнем юк, — ди малай.

Шуннан соң сәүдәгәр кире кайтып китә. Кайта да патшага әйтә:

— Егет килми, падишаһым-солтаным, — ди.

— Килмәсә дә китерегез, — ди патша.

Сәүдәгәрләр хәзер бик ачуланып чыгып китәләр. Егет янына баралар. Егет болар килгәндә әле һаман үз эшендә, су чапылдатып тик ята. Әйтәләр моңа:

— Әйдә патша янына барабыз, — дип.

Егет:

— Бармыйм, — ди.

Шуннан соң моны көчләп, чыбыркылап алып китәләр. Юлда барганда әйтәләр үзенә:

— Патша янында без «әйе» дигәч, син дә «әйе» диген, юкса кирәгеңне бирербез, — диләр.

Алып кайтып патша янына кертәләр моны. Патша утырган җиреннән торып күрешә дә:

— Хәлең ничек, исән-сау килеп җиттеңме? — ди. — Син җибәрдеңме бу бүләкне? — ди. Патша малайга теге гәүһәр ташны күрсәтә. Малай сәүдәгәрләр ягына карый да:

— Әйе, мин, — ди.

Егет шулай дигәч, патша әйтә:

— Минем сиңа бирергә андый бүләгем юк, мин сиңа кызымны бирермен, син шуңа ризамы? — ди.

Шул чакны сәүдәгәрләр егеткә чыбыркы күрсәтәләр.

— Әйе, риза, — ди бу.

Патша эшне озакка сузмый, туй ясап бу егеткә кызын бирә.

Туйлары бер дә харап әйбәт уза. Туй узгач, кыз белән егетне бер бүлмәгә ябып куялар. Бүлмәнең ишеге төбендә бик тирән чокыр була, капкачлы. Аста еланнар, тагы әллә нинди хәшәрәтләр, ди. Патша әмер бирә:

— Ишек төбендәге капкачны ачыгыз, кияү белән кыз янына явыз ният белән килгән кеше чокырга төшеп үлсен, — ди.

Патша әмерен үтәп, чокыр өстендәге капкачны ачып куялар. Инде килик хәзер егет белән кызга. Егетнең акылы юк бит, ул

кыз белән утырган җиреннән сикереп тора да тотына кызны кыйнарга:

— Чыгып кит моннан, ди, каян килдең син, ди, синең миңа кирәгең юк, — ди. Сугыпмы суга кызга. Кыз акырып елый башлый. Чыгып китәр иде, ишек төбендәге чокырны ачып куйганнар. Кыз моны белә. Егет кызны кыйный-кыйный да:

— Ярар, син китмәсәң, мин үзем китәм моннан, — дип качып китмәкче була. Ул шулай дип ишек янына барып, ишекне ачыйм дигәндә генә, Бәхет әйтә Акылга:

— Харап була бит егет, кер тизрәк башына, — ди, — Акыл булмаса, Бәхет белән генә булмый икән ул, —ди. — Егетне шундый дәрәҗәгә менгезеп, әрәм итәбез хәзер, — ди.


Шул вакытта Акыл егетнең башына кереп утыра. Егет ишекне ачар-ачмас уйлый башлый: «Тукта, кая барам соң мин, ди, патша кызына өйләндем бит», — ди. Кыз янына кире килә.

— Ник елыйсың син? — ди.

— Үзең кыйнадың да сорыйсың тагы, — ди кыз.

Егетнең акылы бар хәзер, аптырап калмый.

— Елама, — ди, — безнең якта шундый гадәт: кызны беренче кичтә кыйныйлар, шуңа кыйнадым сине, канатым, — ди. Кызны юата, иркәли. Шуннан соң болар бик әйбәт кенә тора башлыйлар.



БАЛЫКЧЫ УЛЫ ҠАТЫП

Әүвәл-әүвәл заманда булган, имеш, Ҡаюм исемле бер балыкчы бабай. Бабайның карчыгы белән Ҡатып исемле бер малае була. Үзләре бик ярлы яшиләр. Әби карчык йон эрли, ә Ҡаюм бабай һәр көн иртән иртүк тора да китә балык тотарга. Тик күпме генә тырышса да, өчтән артыкны тота алмый. Бабай китергән балыкның берсен саталар да акчага икмәк-тоз алалар. Әби эрләп саткан йон акчасына башка өй кирәк-яраклары алалар. Менә шулай итеп яшиләр.

Көннәрнең бер көнендә уллары Ҡатып әйтә:

— Әти, бир бүген мин балыкка барыйм, — ди.

Бабай белән әби, балалары бер генә булганга күрә, Ҡатыпны җибәрергә куркалар. Шулай булса да, Ҡатыпның хәтерен сындырмас өчен, риза булалар. Ҡатып, бик шатланып, атасының балык тота торган әйберләрен ала да атасы йөри торган күлгә китә. Күл янына килеп җитә дә балык тотарга әзерләнә башлый.

Шул чакта Ҡатып янына атка менгән бер бабай килә дә:

— Исәнме, Ҡатып, — дип дәшә.

Ҡатып, моңарчы бер дә күрмәгән бабайдан үз исемен ишет-

кәч, аптырап кала. Алай да үзенең аптыравын белгертмәс өчен, бабай белән исәнләшә. Бераз сөйләшкәч, бабай әйтә:

— Син кармагыңны суга ташлама, — ди. Шулай ди дә аты өстеннән төшә, төшеп сумкасыннан бер озын бау чыгара.

— Менә шул бау белән минем кулларымны, аякларымны нык итеп бәйлә дә мине суга ташла. Синең ул хезмәтең өчен, мә, сиңа йөз сум акча. Әгәр мин судан кулларым белән югарыга чыксам, миңа су кырыена чыгарга ярдәм итәрсең, әгәр мин аякларым белән судан югары чыксам, мине судан чыгарып шунда күмәрсең. Судан чыгарып күмгән өчен менә шул атым белән ат өстендәге әйберләремне алырсың, — ди.

Катып, бу сүзләрне ишеткәч, бик аптырап кала.

— Юк, бабай, мин кеше үтерүче түгел, мин сине суга ташламыйм, — ди.

Бабай әйтә:

— Мин бик яхшы беләм: син үтерүче түгел, әмма син мине тыңла. Мин ни әйтсәм, шуны эшлә. Мин үзем риза, риза булганга күрә килдем дә бит, — ди.

Катып күпме генә теләмәсә дә, бабай җиңә. Катып бабайның кул-аягын бау белән бәйли дә суга ташлый. Бабайны ташлагач, су кайный башлый. Берничә минуттан бабай судан аяклары белән югары калка. Катып бабайны судан тартып чыгара да кабер казып күмеп куя. Аннан атка менә дә өенә кайтып китә. Өенә кайткач, атасы-анасы Катыпны тиргиләр:

— Ник кеше атын алып кайттың, — диләр.

Катып башыннан үткән хәлне сөйләп биргәч, болар бик шатланалар. Әмма үзләре шундук кайгыралар да: юри мыскыллар өчен яисә кеше үтереп, әйберләрен урладың дип, төрмәгә ябар өчен булмасын, диләр.

Төн үтә, килүче булмый. Катыпның атасы атны иртә белән базарга чыгарып сата да бөтен кирәк әйберләрен алып кайта.

Шулай беркадәр вакыт яшәгәч, боларның акчалары бетә. Катып тагы атасы-анасыннан рөхсәт алып балык тотарга китә. Катып күл янына җитеп балык тотарга әзерләнгәндә, нәкъ теге үлгән бабайга охшаган, шундый ук кием кигән, шундый ук атка менгән бабай килә дә Катып белән исәнләшә.

Қатып моны күргәч бик аптырап кала: «Мин бу бабайны күмгән идем, ди, ничек бу терелде икән», — ди.

Бабай Қатыпка әйтә:

— Син бер дә аптырама. Мә сиңа йөз сум акча, минем абыемны ничек күмдең, мине дә шулай күм, — ди.

Қатып, бу сүзләрне ишеткәч, курыкмыйча, бабайның куляягын бәйли дә суга ташлый. Бу бабайны ташлагач та, су кайный башлый. Бераздан соң, бабай аякларын күтәреп судан чыга. Қатып моны күргәч: «Я, ярый, моның да аты миңа калды», — дип, бабайны судан алып, тагы да чыга алмасын дип, бик тирәнгә күмә. Ә үзе атка менә дә өенә кайтып китә. Бу атны да шулай чыгарып саталар.

Тагы берникадәр вакыттан соң, Қатып балык тотарга чыгып китә: моның әтисе чирле була. Қатып күл янына килеп җиткәч, ни күрсен, тагы шул ук бабай шундый ук атка атланып килә. Бабай Қатып белән исәнләшә дә теге бабайлар кебек үк әйтә. Қатып хәзер өйрәнеп җитте инде, бабайның куляягын бик каты итеп бәйли дә суга ташлый. Су шулай ук кайный башлый да, берничә минуттан соң бабайның куллары күренә. Қатып бабайны судан тартып чыгара. Бабай судан чыккач:

— Я, улым Қатып, бик зур рәхмәт сиңа, ди. Ике абыема насыйп булмаган, ә миңа насыйп булган икән, ди. — Сумкасыннан бер ашъяулык чыгара да: — Син дә арыдың, ачыккансың, мин дә ачыктым, кил икәүләп ашыйк, — ди дә ашъяулыкны җәеп җибәрә. Ашъяулыкта ни теләсәң шундый ашлар була. Болар бик әйбәт кенә ашыйлар. Ашъяулыкта калган ашларны бабай җиргә ташлый. Қатып бу эшкә бик исе китеп кала.

— Бабай, үзең карт кеше, үзең ашларны җиргә ташлыйсың, — ди.

Бабай әйтә:

— Ул ашъяулыкның хасияте шул: калган ашны ташламасаң, өч көн аш бирми, — ди.

Болар ашап, ял иткәч, бабай Қатыпка әйтә:

— Әйдә минем белән бер айга эшкә, ди, эш хакың өчен,

мә, йөз сум акча, атаңа-анаңа илтеп бир, — ди. Шулай ди дә Катыпны өенә озата.

Катып өенә кайтып йөз сум акчаны бирә дә эшнең ни икәнен сөйли. Катыпның ата-анасы бердәнбер балаларын күз алларыннан ниндидер ят бер картка ышанып җибәрергә риза булмыйлар. Әмма, Катып бик инәлеп сораганга күрә, Катыпның ата-анасы ризалык бирә. Шуннан соң Катып саубуллашып чыгып китә. Катып күл янына килгәндә, теге бабай ике ат белән көтеп тора икән. Бабай атның берсен Катыпка бирә, ә берсенә үзе атланып, юлга чыгалар.

Шулай итеп, кичкә хәтле баралар болар. Кич булгач, бабай Катыпка әйтә:

— Көн буе юл килдек, арыдык, ашыйсы да килә. Менә шунда бераз ял итик, — ди.

Туктап, аттан төшәләр дә атларны болынга җибәрәләр. Ә үзләре бер шалаш ясап, ашап-эчкәч, кереп яталар. Катып атларны карарга бармакчы була, ләкин бабай аны туктатып әйтә:

— Син, улым, атлар өчен бер дә борчылма, алар безгә кирәккән чакта һәрвакыт яныбызда булырлар. Син ят, ял ит, иртән иртүк юлга чыгарбыз, — ди.

Катып, бу сүзләрне ишеткәч, әйбәт кенә ятып йоклый. Иртән Катып йокысыннан уянган вакытта, атлар болар янында була инде. Торып юыналар. Шул ук ашъяулыктан ашап-эчкәч, калган ашларны җиргә ташлыйлар да, атларына атланып, юлга чыгалар. Тагын шулай берничә вакытлар юл киткәч, җитәләр бер диңгез читенә.

Бабай шунда Катыптан сорый:

— Я, Катып, ничә көнлек юл килдек инде? — ди.

Катып әйтә:

— Өч көнлек, — ди.

Бабай әйтә:

— Юк, улым, өч көнлек түгел, өч айлык юл килдек инде, — ди.

Катып бу сүзләрдән бик аптырап кала. Бабай моны аңлап ала да әйтә:

— Син, Катып, бер дә аптырама, бер дә курыкма. Безгә менә шул диңгезне кичәргә кирәк. Шуның өчен син бер тылсым догасы өйрәнергә тиешсең. Шуны өйрәнгәнче, без шушында яшәрбез, — ди. Шулай ди дә Катыпка сихер догасы өйрәтә башлый.

Катып бик аңлы булганга күрә, ике көндә үк өйрәнеп җитә бу доганы. Шуннан соң атларына атланалар да, бабай әйтә:

— Йом күзләреңне, ә үзең шул доганы укы. Мин кушмыйча күзләреңне ачма, — ди.

Юлга төшеп бераз баргач, бабай Катыпка әйтә:

— Күзләреңне ачып карале, — ди.

Катып, күзләрен ачса, куркып кала, чөнки болар диңгез төбеннән баралар икән. Ә су туннел кебек булып аерылып тора. Катып янә күзләрен йома. Берничә вакыт баргач, бабай әйтә:

— Улым, ач күзләреңне, — ди.

Катып, күзләрен ачып караса, үзләрен диңгезнең аръягында коры җирдә икәнен күрә. Болар янә ашап-эчеп ял итәләр дә юлга төшәләр. Берничә вакыт баргач, җитәләр олы гына, түгәрәк кенә тау янына. Шунда бабай әйтә:

— Менә, Катып, без җиттек эшебез янына, — ди.

Аттан төшеп, атларны җибәрәләр. Шунда инде бабай сүз башлый:

— Хәзер мин тылсым укыйм, минем тылсымнан бу тау бетәр. Шул тау астында бер ишек булыр, ул ишеккә синең исемең язылган. Синнән башка беркем дә анда керә алмый. Шуңа күрә мин сине бире китердем дә. Син, ул ишек күренгәч, ишек янына бар да дөбердәт. Синнән сорарлар: «Кем анда», — дип. Ә син әйт: «Балыкчы малае Катып, ач ишекне», — дип. Шул вакыт ишек ачылыр. Син ишектән кергәч, синең өстеңә ике олы эт килер, син алардан бер дә курыкма, алар тылсымнар гына. Син бер адым алга атлагач ук, алар юк булыр. Шуннан соң икенче ишектән керерсең. Анда ике арслан булыр. Алардан да курыкма, алары да тылсым гына. Стенада камчы булыр, шул камчыны ал да өсләренә селтә, алар юк булыр. Шуннан соң өченче ишектән керерсең, анда өстеңә ут килер. Шул камчыны

утка ташла, ут сүнәр. Дүртенче ишеккә керерсең, анда анаңа охшаган бер карчык булыр. Кара, иң авыры шул: син аны кызганма, җәлләмә, аңа ышанма, ул анаң түгел, тылсым гына. Әгәр кызгансаң, харап булырсың. Син аңа чишенергә куш, кара, үзеңә якын җибәрмә. Кадакта элгән кылыч булыр, шуны ал да: «Әгәр якын килсәң, чишенмәсәң, башыңны чабып өзәм»,— диген. Тик, кара аны, ул елар, каргар, чишендермә, дип ялварыр, әллә нинди сүзләр әйтер, син аңа бер дә ышанма, чишендер. Ул чишенгәч, бишенче ишек күренер, анда өстәл булыр, өстәл өстендә стакан эчендә бер алтын йөзек булыр. Шул алтын йөзекне алуга, минем янга чыгарырлар. Ләкин, кара аны, курыкма да, кызганма да, ату харап булырсың,— ди.

Катып ризалык биргәч, бабай догасын укый башлый, тау юк була. Тау астында бер тимер ишек күренә. Катып ишекне барып дөбердәтә. Ишектән:

— Кем анда, ни кирәк? — дигән тавыш ишетелә.

Катып шунда:

— Мин балыкчы малае Катып, ач ишекне,— ди дә, ишек ачылып китә.

Катып ишектән эчкә керә. Керсә, өстенә ике олы эт өреп килә. Катып курыкмый, алга атлый. Шунда этләр югала. Икенче ишек ачыла, Катып ишектән керә. Өстенә ике олы арслан акырып килә. Катып камчыны ала да болар өстенә селтәнә, арсланнар шундук юк булалар. Өченче ишек ачыла. Катып ишектән керә. Керсә, өстенә ялкынланып ут килә. Катып аптырап калмый, утка камчыны ташлый да ут шундук сүнә. Дүртенче ишек ачыла. Катып ишектән керсә, анда утырган әнкәсен күрә. Бу тылсымлы карчык:

— Әй бәпкәм, бәгырем, ике күз нурым, кай җирләрдә йөрдең? Ул бәдбәхет бабай аптыраткандыр, аш-сусыз йөрткәндер,— ди, тагы шундый ягымлы сүзләр әйтеп, Катыпка каршы килә, кочакларга тели. Әмма Катып аптырап калмый, тиз генә кылычны ала да:

— Миңа якын килмә, тиз генә чишен,— дип әмер итә. Карчык, бу эшне күргәч, барып урынына утыра да Катыпны тиргәп-тиргәп елый башлый. Катып, әнкәсенең елавын күргәч,

бабайның әйткән сүзләрен оныта да күңеленә кызгану хисе килә. Шул вакыттан Катып бер ни дә белми, чөнки күңеленә кызгану хисе кергәч, аны тылсым көче белән күккә ыргыталар. Ләкин бабай Катыпны җиргә төшеп бәрелергә бирми, тотып ала да төрле дарулар белән дәвалый башлый. Өч көннән соң Катып аңына килә. Бабай шунда Катыпка әйтә:

— Мин сиңа әйттем, син бер нәрсәдән дә курыкма, бер нәрсәне дә кызганма дип, син, дөрес, курыкмадың, ләкин ул тылсымны кызгандың. Ярый әле мин сине вакытында тотып алдым, югыйсә үлгән идең, — ди.

Катып әйтә:

— Укы тагын бабай, керәм, — ди.

Бабай әйтә:

— Ул ишек елына бер генә көнгә ачыла, шуңа күрә без синең белән шунда бер ел көтәргә тиешбез, — ди.

Катып риза була. Бер ел шунда яшиләр. Бер ел үткәч, бабай тагы укый догасын, Катып тагы керә. Хәзер инде бер дә курыкмыйча әүвәлге өч ишекне үтә. Дүртенче ишеккә керә. Анда күрә әнкәсен. Катып кергәч, әнкәсенә охшаган тылсым:

— Әй бәгырем, балам, бер ел кая йөрдең, ничек кайттың? — дип елый-елый Катып янына килмәкче була. Катып тиз генә кылычны ала да:

— Тиз чишен, ату башыңны кисәм, — ди.

Тылсым карчыгы ничек кенә Катыпка «чишендермә» дип ялвармасын, Катып фикер бирми. Шунда тылсым карчык чишенә дә юк була. Бишенче ишек ачыла. Катып керә ишектән. Стаканнан алтын йөзекне ала. Йөзекне алуга бабай янына килеп тә чыга. Бабай Катыптан йөзекне бик шатланып ала да:

— Я, Катып улым, сиңа дөньяда нәрсә кирәк, бөтенесен эшлим, — ди.

Катып уйлап тора да:

— Миңа теге ашъяулыкны бирсәң, җитәр, — ди.

Бабай ашъяулыкны Катыпка бирә.

— Тагын нәрсә кирәк, — ди.

Катып бабайдан сорый:

— Бу йөзекнең хикмәте нәрсә? — ди.

Бабай монысын әйтми.

— Я, Катып, кайчан авыр көнең булыр, шул вакыт, «кил, бабай», — дип мине чакырырсың, мин янында булырмын, — ди дә Катып белән саубуллаша, аннары Катыпка күзләрен йомарга куша. Катып күзләрен йома. Шул вакыт җил искән кебек булып китә, Катыпның аяклары нәрсәгәдер бәрелгән кебек була. Катып күзен ачып караса, үзен балык тота торган күл янында күрә. Шуннан өенә кайтып китә. Ә өендә атасы бөкрәйгән, анасы елап сукырайган, чөнки Катып бер айга дип киткән иде, ә ул бер ел торып кайтты. Ашарга икмәкләре беткән. Атасы балык тотарга йөри алмый, бик картайган, анасының йон эрләргә күзләре күрми, тик тирә-күршеләре биргән кисәкләр белән генә яшиләр. Ә Катып калдырган акчаны балыкчы бабайның бер бик бай, бик саран энесе килеп алган да бирмәгән. Катыпның атасы барып сораган, ләкин аны акча бирмичә куып кына чыгарганнар. Менә шулай итеп, болар, карт белән карчык, Катып киткәч, ач яшәгәннәр.

Катып бабайдан алган ашъяулыкны җәя дә, болар бик әйбәтләп ашыйлар, эчәләр, тук булалар. Ә калган ашны Катып чыгарып ташлый. Менә шулай әйбәт кенә яшиләр. Катып бөтен ярлы-фәкыйрь тирә-күршеләрен һәр көн ашата. Катыпка ашханә ачарга әйтәләр. Шунда син бик баерсың, диләр. Әмма Катып ашханә ачмый, әйтә:

— Миңа байлык кирәкми, — ди. — Ашханә ачсам, халыкны акчага ашатырга тиешмен. Ә болай мин халыкны акчасыз гына ашатам, — ди.

Шулай яхшы гына яшәгәндә, бу ашъяулык турындагы хәбәрне теге бай абыйлары ишетә дә Катыпларга кунакка килә. Моны бу ашъяулыктан яхшы ашлар ашаталар, төрле эчемлекләр эчертәләр. Бу саран бай ачуыннан, кызыгуыннан шартлый башлый, ләкин ничектер шартламый, тик тугыз кило мае гына кими. Бу бай икенче көнне бара патшага.

— Әй кадерле, көчле падишабыз, ди, синең миңа ачуың чыкмасын. Минем балыкчы абыемның бер малае бар, Катып исемле. Ул әйтә: әгәр падиша рөхсәт итсә, мин аңа кырык мәртәбәле бер сарай салыр идем, кайсына бу дөньяда тиң юк, — ди.

Патша бу хәбәрне ишеткәч, Катыпны чакырта. Чакырта да кырык мәртәбәле сарай ясарга куша. Өстәвенә Катыпны сүгә.

— Ник үзең килеп әйтмичә абыеңнан әйттерәсең, ул карт кешене йөртәсең, — ди.

Ә Катып күпме генә: «Мин андый сүзләр сөйләгәнем юк, мин сарай сала белмим», — дип, патшаны ышандырырга теләсә дә, патша Катыпның сүзләренә ышанмый. Моңа кырык көн вакыт бирә. Шуннан соң Катып кайгырып чыгып китә.

Юлда барганда Катыпка бик карт бер бабай очрый. Болар исәнләшәләр. Катып бабайны танымый. Бабай әйтә:

— Я, улым Катып, кая барасың, ниләр эшләп йөрисең?— ди.

Катып эшнең ни икәнен сөйләп биргәч, бабай әйтә:

— Мин сиңа әйткән идем, башыңа бәла килсә, мине сагын, дип. Ә син мине исеңнән чыгардың, оныттың, — ди.

Катып шул вакыт бабайны таный да тагын бер кат исәнләшәләр. Шунда бабай әйтә:

— Мин картайдым инде, тиздән үләм. Мине дә күм абыйларым янына, ди. Ә йөзек синең исемеңә язылган, мә аны. Шул йөзек белән, дөньяда нинди эш бар, бөтенесен эшләрсең, — ди дә йөзекне Катыпка бирә. Үзе шунда үлә. Катып бабайны күмә дә кире патша янына борыла.

— Мин моңа күрсәтим әле ничек сарай саласын, — ди. Йөзекне селкеп җибәрүгә, чыга гаскәр, чыга гаскәр. Шул гаскәр белән патшаны да, байларны да пыран-заран туздырып ташлый бу. Шуннан соң Катып үзенең ашъяулыгы белән бик иркенләп, тынычлап әле дә булса ярлы, ач халыкны туйдырып тора, ди.



ТӨШЕҢНЕ СӨЙЛИСЕҢМЕ?

Борын заманда бер ярлы гына карчык була. Моның бер малае була. Егет унбиш яшькә җиткәч, карчык малаен бирә бер итекчегә өйрәтергә. Элек бит сигез сәгать кенә эшләмәгәннәр, көннәр буе эшләгәннәр.

Шул вакытларда патша әйтә вәзиренә:

— Әйдә, ди, шәһәрне бер әйләнеп чыгыйк әле, нәрсә бар икән, халык безнең турыда нәрсә сөйли икән, — ди.

Йөри-йөри болар кичкә калалар. Беркайда ут юк. Кайда кунарга инде? Йөри торгач, бер өйдә күрәләр ут. Керәләр. Керсәләр, теге итекче өйрәнчеге белән эшләп утыра. Төн буе сөйләшеп чыгалар болар, төн бик күңелле үтә. Утыра торгач, итекче күрә: малае йокыга киткән. Итекченең бик ачуы килеп уята моны. Малай әйтә:

— Их, ди, тагын бераз гына йокларга бирмәдең, шундый матур төш күрә идем, ахырына кадәр күреп бетерергә бирмәдең, — ди.

Итекче:

— Сөйлә төшеңне, — ди.

— Юк, сөйләргә ярамый, — ди егет.

Патшаны да, вәзирне дә тыңламый, төшен сөйләми бу.

Патша өенә кайткач әйтә:

— Фәлән җирдә бер итекче бар, шунда бер малай эшли. Менә шуны миңа китерегез, — ди.

«Нәрсәгә минем кирәгем бар икән патшага», — ди егет. Ә патша егетнең күргән төшенә кызыга.

Баргач, керәләр патша йортына. Патша әйтә:

— Кичә күргән төшеңне сөйлә, — ди.

— Юк, ди, сөйли торган төш түгел ул, мин аны беркемгә дә сөйләмим, — ди.

Патша төрлечә әйтеп карый.

— Мал бирәм, ди, йорт-җир бирәм, — ди.

— Сөйләмим, — ди егет.

— Астырам, кистерәм, үтертәм, — ди патша. Һаман да:

— Теләсәң нишләт, сөйләмим, — ди егет.

— Ярар алай булса, — ди патша, — бирегез үзенә биш камчы, аннан чыгарып ябыгыз, — ди.

Егетне кыйнап, чыгарып ябалар. Иртәгесен тагын сорый патша. Тагын сөйләми. Биш камчы бирәләр дә чыгарып ябалар. Берничә көннәр үткәч, патшаның кызы егет тәрәзәсе яныннан үтеп бара. Кыз сорый төрмә башлыгыннан:

— Кем утыра монда? — ди.

— Әй, бер җүләр егет, ди, төшен сөйләми, ди, шуның өчен падишаһыбыз һәр көн чакыртып суктыра, — ди.

— Карарга ярыймы? — ди кыз.

— Ник ярамасын, ди, кара, — ди төрмә башлыгы.

Кыз төрмә ишеген ачып карый, егет шундый матур, шундый сылу. Кыз гашыйк була егеткә. Кыз, өенә кайткач, останы чакыра да әйтә:

— Шул егет утыра торган бүлмәдән безнең бакчага чыгарга бер төн эчендә юл яса, ди. Ябылгач, ишеге беленерлек булмасын, ди. Шуны эшләсәң, йөз сум акча бирәм, — ди.

Оста бик риза инде, нихәтле акча ала бит.

Икенче көнне төшен сөйләмәгән өчен егетне тагын кыйнап кертеп ябалар бит инде. Кыз шуны гына белә дә, марля, йод

алып, теге яшерен юлдан егет янына кереп, дәвалый. Егетне тәрбияли башлый. Тәмле әйберләр китерә. Кыз һәр көнне егет янына кереп чыга. Ә патша һәр көнне егетне суктыра.

Көннәрнең берендә патшага икенче патшадан хәбәр килә: «Кызыңны бир, кызыңны бирмәсәң, җибәргән табышмакларга җаваплар әйт, яки сугыш ачам», — дип.

Ул патша җибәргән өч алма. Өчесе дә бертөсле. Шуларның кайсы быелгы, кайсы былтыргы, кайсы өченче елгы — шуны белергә кирәк.

Бу патша вәзирен чакырта, бөтен карт-корыны чакырта. Барысыннан да сорый, һич белүче юк. Бу хәбәрне патшаның кызы ишетә дә егеткә килеп әйтә. Кыз әйтә:

— Мин синең белүеңә ышанам, — ди. — Син болай гына әйтмә, ди, кызыңны бирсәң, әйтәм диген, — ди.

Ярар, белүче юк бит инде. Патша әйтә:

— Чакырыгыз әле теге егетне, — ди.

Егет керә.

— Сөйлисеңме төшеңне? — ди.

— Юк, сөйләмим, — ди.

— Ярар, сөйләмәсәң сөйләмә, ди, алайса менә шушы алмаларның кайсы быелгы, кайсы былтыргы, кайсы өченче елгы икәнен аерып бир, — ди.

— Мин болай гына җавап бирмим, ди, кызыңны миңа бирсәң, әйтәм, — ди.

Патша көлеп җибәрә, ә вәзире әйтә:

— Син риза дип әйт, соңыннан күз күрер, — ди.

Патша:

— Ярар, ди, дөрес җавап бирсәң, бирермен, — ди.

— Китерегез бер савыт су, — ди бу.

Егет алмаларны суга сала. Алманың өчесе өч урында тора: берсе суның төбенә төшә, икенчесе — суның уртасында, өченчесе суның өстендә генә кала.

— Менә, ди, су төбенә төшкәне быелгы алма, ди, уртарак җирдә торганы — былтыргы, су өстендә торганы өченче елгы алма, монысы кипкән инде, — ди.

Теге патшалыктан килгән кешедән сорыйлар: «Дөресме?»

дип. «Дөрес», — ди. Шул гына кирәк бит инде. Патша егеттән тагын сорый:

— Төшеңне сөйлисеңме инде? — ди.

— Юк, сөйләмим, — ди.

Тагын камчы белән суктыралар да чыгарып ябалар моны. Ә кыз егетне күтәп кенә тора бит инде.

— Әйттеңме? — ди.

— Әйттем, — ди.

Теге илче кеше бу егетнең дөрес җавап биргәнен белде бит инде. Хәзер бу кеше бер агач алып килә. Агачның ике башы да бертигез, бер юанлыкта. Шул агачның кайсы очы төп, кайсы очы баш икәнен белергә кирәк.

Илче килә дә патшага әйтә:

— Менә шушы агачның кайсы очы төп, кайсы очы баш, шуны белергә кирәк, — ди.

Тагын егетне чакырып әйтәләр. Егет әйтә:

— Мин болай гына әйтмим, кызың бирсәң генә, әйтәм, — ди. — Тик кәгазь язып, пичәтеңне куйсаң гына әйтәм, коры сүзгә генә ышанмыйм, — ди.

Вәзирләр әйтәләр:

— Яз, сиңа бер кәгазь язганнан ни булган, — диләр.

— Ярый, — ди патша, — кәгазь дә язам, пичәтен дә куям, — ди.

— Китерегез бер савыт белән су, — ди егет.

Су китерәләр. Сала агачны суга. Агачның бер башы су төбенә батып тора, икенче башы су өстенә калыккан.

— Менә бу башы төп, бусы — баш, — ди.

— Дөрес, — ди килгән кеше.

Тагын шул егет тапты, дип кайтып әйтә илче патшага.

Өченче табкырында илче китерә өч ат. Өчесе дә бер буйда, бер төстә, бер зурлыкта. Шуларның кайсы карт, кайсы яшь икәнлекне белергә кирәк.

Патша әйтә:

— Китерегез әле теге егетне, — ди. Китерәләр.

— Шушы атларның кайсы карт, кайсы яшь икәнлекне беләсеңме? — ди.

— Беләм, — ди егет.

— Белсәң — әйт, — ди.

— Юк алай гына әйтмим, ди. Әгәр дә кызың белән икебезгә никах укытсаң, әйтәм, — ди.

Нишләсен патша? Риза була инде. Укыта никахны. Аннан соң егет әйтә:

— Китерегез бер савыт сөт, ди, бер бәйләм печән, бер тубал солы, — ди.

Китерәләр сораган әйберләрне. Өчесен өч төшкә куялар. Атларны җибәрәләр. Атларның берсе килә сөткә, икенчесе печәнгә, өченчесе солыга.

— Менә, ди, сөткә тыгылганы бер яшьлек, — ди.

— Нидән алай? — ди патша.

— Чөнки, ди, әле ул яшь, сөт тәмен генә белә, артык берни белми, — ди.

Атның икенчесе печәнгә тыгыла.

— Монысы инде сөт тәмен оныткан, печән тәмен генә белә, ди. Ә солы ашарга тешләре үтми әле, — ди.

Өченчесе солыга тыгыла.

— Аның тешләре каткан, солыны да ашый ала, монысы иң карты, — ди.

Илчедән сорыйлар:

— Дөресме?

— Дөрес, — ди.

Шул гына кирәк тә. Хәзер инде патша кызын бирсә дә бирә, бирмәсә дә бирә: бөтен сорауларга җавапны шул егет тапты. Патша шул чакны егеттән сорый:

— Инде төшеңне сөйлисеңме? — ди.

— Хәзер сөйләсәм дә була, — ди егет. — Мин, ди, төшемдә синең кызыңа өйләнгәнемне күрдем, ди, патша кияве булып туйга бардым, ди. Төшем рас килде менә, ди. Әйдә туй итик, — ди.

Шатлыктан зур итеп туй ясыйлар. Туйга бөтен халыкны җыялар. Мин дә анда идем. Их, туй шундый шәп булды! Туйда китерделәр өч алма: берсе — сиңа, икенчесе — миңа, өченчесе — әкият сөйләүчегә, диделәр. Алмалар кемнәргә булган?



ПАТША МАЛАЕ БЕЛӘН ХЕЗМӘТЧЕ МАЛАЕ

Бик борын заманда яшәгән, ди, бер патша. Бу патшаның кыз балалары бик күп булган, ә ир баласы бер дә булмаган. Шуңа күрә бу бик борчылган, кайгырган.

Узган-барган дәрвишләргә, теләнчеләргә хәер-сәдака биргәндә:

— Алладан сорагыз, миңа бер ир бала бирсен, — ди икән.

Шулай көннәрнең бер көнендә бу патшага бер дәрвиш капчыгыннан бер балык чыгарып бирә дә:

— Менә шул балыкны пешереп, үзең генә аша, — ди. Шулай ди дә дәрвиш патша йортыннан үз юлына чыгып та китә.

Патша балыкны аш-су хәзерләүче хезмәтчесенә бирә дә әйтә:

— Кара, бу балыкны беркем дә ашамасын, — ди.

Хезмәтче балыкны әйбәт иттереп арчый, куыра. Шулай да тозын-тәмен карамыйча куырылган балыкны патшага бирергә курка. Шуңа күрә балыкның бер кисәген алып ашый. Ә кал-

ганын патшага бирә. Бу хезмәтченең дә ир баласы бер дә булмаган икән.

Бу балыкны ашаганнан бер ел үткәч, бер үк көндә, бер үк сәгатьтә патша хатыны да, хезмәтче хатыны да берәр ир бала тудыралар. Бу ике бала бер-берсенә шундый охшаган булалар, хәтта үз туган аналары да кайсы үз баласы икәнен танымыйлар. Бу балалар шундый тату яшиләр, берсе-берсеннән бер дә аерылышмыйлар.

Шулай болар унсигез яшькә җиткәч, патша малае бер көнне төшендә бер кыз күрә дә гашыйк та була. Төшендә кыз бу малайга әйтә:

— Әгәр мине яратсаң, кил яныма, ди. Мине табар өчен биш диңгез кичәрсең, биш патшалык үтәрсең, шуннан мине табарсың, — ди.

Шуннан соң, патша малае бу төшендә күргән кыз хәсрәтеннән ашамый-эчми, көннән-көн ябыга бара. Хәсрәтен үз иптәшеннән башка беркемгә дә сөйләми. Хезмәтче малаена да беркемгә дә сөйләмәскә куша.

Патша исә, улым каста дип, нинди генә докторлар чакырса да, моның чирен берсе дә белми.

Шуннан патша кече кызын чакыра да:

— Сине энең бик ярата. Син аңардан чире ни икәнен сораш, аннан миңа әйтерсең, — ди.

Патшаның кече кызы энесенең кайгы-хәсрәтен сорашып белгәч, атасына малайның төшендә кыз күреп гашыйк булганын, ул кыз ничек үзен эзләргә кушканын, шул кыз хәсрәтеннән малайның корып кипкәнен сөйләп бирә. Патша, кызыннан бу сүзләрне ишеткәч, шатлана да, кайгыра да. Патша малаеның өйләнергә теләвенә шатлана. Ә инде бу кызны эзләгәндә күпме мал әрәм китүенә, күпме михнәт, мәшәкать кирәгенә кайгыра. Шулай булса да, патша кораб ясата. Йөз солдат бирә, корабка биш еллык азык, кирәк-яраклар төятә. Юл әйберләре әзер булгач, патша малае белән хезмәтче малае аталары-аналары белән саубуллашып, йөз солдатны алып, корабка утырып китәләр. Патшалар, хезмәтчеләр елашып калсыннар, ә без сезнең белән китик малайлар белән.

Болар көн баралар, төн баралар, ай баралар, ел баралар, карыш буе җир баралар. Юлда барганда бервакыт диңгездә давыл күтәрелә. Корабны ары бәрә, бире бәрә. Бәрә торгач, боларның кораблары чыдамый, челпәрәмә килә. Күбесе бата, кайберләре котыла. Патша малаен дулкын бәреп су кырыена чыгара. Ул исән-сау өенә кайтып керә. Без китик хезмәтче малае белән.

Бу егет, кораб ватылгач, бер тактага ябыша да, давыл моны өч көн йөрткәч, бер ярга китереп ташлый. Бу шунда ял итеп азмы-күпме яткач, күзләрен ачып караса, бу бер олы урман янында диңгез буенда икәнен күрә. Шуннан бу диңгездә батмый котылуына бик шатлана да, тамак туйдырырга берәр әйбер тапмаммы дип, шул урманга кереп китә. Урманда моны маймыллар тотып алалар да:

— Әй адәм баласы, без адәмне гомеребез буена эзләп йөрибез. Кил, зинһар, безгә патша бул, югыйсә безгә аюлар көн күрсәтмиләр, бөтен байлыгыбызны талыйлар, — диләр.

Шулай итеп, маймыллар бу егетне үзләренә патша итеп куялар.

Аюлар, маймылларның патшалары адәм икәнен белгәч, куркуларыннан маймылларны таламый башлыйлар.

Бу егет маймыллардан качып котылмакчы да була, әмма маймыллар, бу эшне сизеп, моны кире тотып китерәләр дә моңа бик көчле сак куялар. Шуннан соң бу маймыллардан котылуның башка юлын эзли башлый.

Беркөн бу егет бал эчетә. Бал бик әйбәт булып чыга. Бу балны эчә дә җырлый-бии башлый, күңел ача. Бу егет балны эчеп ничек кәефләнгәнен маймыллар карап торалар да үзләре дә эчәләр, бииләр, көләләр. Бик каты исерешеп, кайсы кая егылып, йокыга китәләр. Бу егет, бу хәлдән файдаланып, маймыллар кулыннан котыла. Маймыллар җиреннән чыккач, моны аюлар тотып алалар да үзләренә патша итеп куялар. Боларның күршеләрендә бүреләр җире була. Шуңа күрә бүреләр аюларны һәрвакыт талап торалар икән. Аюларга кеше патша булганны белгәч, бүреләр, кешедән куркып, аюлар җиренә кереп талауларын бетерәләр.

Бу егет аюлар кулыннан берничә мәртәбә качып котылмакчы була. Аюлар, бу эшне сизеп, моның янына көчле сак куялар. Аюлар кулыннан болай гына котыла алмаганын белгәч, бу егет аюларның бал амбарындагы бөтен балларын җиргә агыза. Аюлар балның җирдән агып барганын күрәләр дә, дөньяда бөтен нәрсәне онытып, акырышып-бакырышып бал ашарга йөгерәләр. Шул вакыт теге аюлар җиреннән качып китә. Аюлар җиреннән чыгуга, аны бүреләр тотып алалар да үзләренә патша итеп куялар.

Бу егет бүреләрдән дә качып котыла алмасын белгәч, бүреләрнең сарык абзарын ача да бөтен сарыкларны кырга куып чыгара. Бүреләр улаша-улаша сарыклар артыннан куып китәләр. Бу егеткә шул гына кирәк тә. Ул бүреләр җиреннән дә качып китә.

Шулай итеп, бу бервакыт килеп җитә бер бик матур шәһәргә. Шәһәргә барып кергәч, бу бик гаҗәпләнә: һәр почмакта, һәр баганада бу үз рәсемен ябыштырып куйганнарын күрә. Бу, минем рәсемем каян боларга килгән дип, гаҗәпләнеп торганда, моны тотып алалар да патша йортына илтәләр. Бу җирдә теге патша малае төшендә күргән кыз патша булып тора икән. Бу кыз да шул ук кичтә әлеге хезмәтче малаен төшендә күргән икән дә аңа бик каты гашыйк булган икән. Кыз үзе бик яхшы художник булганга күрә, егетнең рәсемнәрен үзе ясап бөтен урамнарга ябыштырткан икән дә:

— Кем кайда шул егетне күрсә, минем яныма алып килсен, — дигән икән.

Бу егетне кыз тәрәзәдән күргәч, каршы чыга да:

— Хуш килдең, мәрхәбә килдең, минем шатлыгымны, мәхәббәтемне, якты тормышымны китердең, — ди.

Егетне мунча кертә, коендыра, яхшы әйберләр киендерә, ашата-эчертә, ял итәргә яткыза. Бу егет бик әйбәт ял итә. Шуннан соң, торгач, кызга башыннан үткәннәрне бөтенесен бәйнәбәйнә сөйләп бирә. Кыз моның сөйләгәнен тыңлап торганнан соң, утырган урыныннан торып егетне кочаклап ала да:

— Миңа куркак патша малае кирәкми, син минеке, мин синеке, — дип бик каты үбә.

— Юк-юк, мин үземнең якын иптәшемә хыянәт итмим, мин сезне аңарга алып барып тапшырырга тиешмен, — ди.

— Син, егетем, бүре белән сарыкның дус булганын ишетмәгәнсең дә, ишетмәссең дә, ул синең иптәшең түгел. Җил икәү бергә шатлыклы гомер итик, — ди.

Кыз бу егетне күпме генә үз ягына аударырга теләсә дә, егет кызның тәкъдимен кабул итми. Шуннан соң кыз әйтә:

— Алай булса, синең якын дустың патша малаен сынап карыйк, әйдә киттек, — ди.

Бу кыз диюләр патшасы булган икән.

Кыз бөтен диюләргә:

— Безне шундый-шундый җиргә күчерегез, минем әмеремнән башка берегез дә кеше күзенә күренмәсен, — ди.

Болар күзләрен йомып ачканчы, егет күрә үз туган шәһәре янында икәнен. Шуннан кыз бер диюне чакырып ала да үз төсенә кертә, ә үзе бер тычканга әйләнә дә егетнең кесәсенә кереп ята.

Шуннан бу егет кызга әйләнгән диюне кулыннан тота да патша йортына алып китә. Бу егетнең атасы-анасы, малайлары үлгәндер инде дип, бик елашкан булалар. Шул хәсрәттән хезмәтче белән аның хатыны икесе дә сукыраялар. Болар сукыраеп, эшкә ярамагач, яшь патша боларга ашарга икмәк тә бирмәгән. Боларны тирә-күршеләре генә ашатып торганнар. Малайлары кайтканга, атасы-анасы бик шатланалар. Малайлары белән килгән кыз каршына куярга бер кисәк ипиләре дә булмагач, болар бик оялалар.

Патша малае, хезмәтче малаеның исән кайтып килгәнен, үзе белән бик матур кыз да алып кайтканын ишеткәч, моның янына кыз карарга дип керә. Керсә, күзе белән ни күрсен, бу кыз төшендә күргән кызы булып чыга. Хезмәтче малае патша малае белән исәнләшергә тели. Шунда патша малае исәнләшү урынына:

— Синең ни хакың бар патшаң сөйгән кызны алырга, — дип кычкыра башлый.

— Юк, иптәшкәй, мин аны сиңа китердем, мин якын

дустыма беркайчан да хыянәт итмәм, — ди. Патша малае шаркылдап көлә генә.

— Беләм мин сезне, хәерче малайларын. Хәзер үк бу оятсыз кабахәтне зинданга салыгыз, иртәгә дарга астырырмын,— ди. Аннан соң теге дию-кызга әйтә:

— Әйдә, җаным, мин синең хәсрәтеңнән саргаеп үләм инде, әйдә, күз нурым, өйгә, — дип алып китә. Хезмәтче малаен зинданга ябалар. Шунда теге кыз тычканнан кире кызга әйләнә дә:

— Я егет, әйттемме мин сиңа, патша белән ярлы кеше дус булмый дип. Тик син бер дә курыкма, иртәгә без аның үзен көлкегә калдырырбыз, ди.

Шулай ди дә кире тычканга әйләнеп малайның куенына кереп ята.

Патша малае, шатлыгыннан дөньясын онытып, төн буена туйга әзерләнә. Иртә булгач, барабаннар кагалар, быргылар кычкырталар, патшаның дар агачы янына бөтен халык җыела. Халык җыелып беткәч, хезмәтче малаен дар агачы янына китерәләр. Хәзерлек беткәч, малайның куеныннан теге тычканга әйләнгән кыз сикереп чыга да, киредән кызга әйләнеп, диюләргә шәһәрне чолгап алырга куша. Ә теге патша янында утырган кыз-диюгә:

— Ә син патшаны бире, дарга, алып кил, — ди.

Бөтен халыкның исе китә мондый гаҗәп эшкә. Патшаны дар агачына сөйрәп киләләр. Шунда бу кыз әйтә:

— Я егет, күрдеңме инде патшаңның, синең якын дустыңның кем икәнен? — ди. — Син нинди михнәтләр чигеп, мине табып китердең, ә ул сине нишләтте? — ди.

— Күрдем, — ди егет.

Шуннан соң патшаны дарга асып куялар. Халык та бу эшне дөрес, ди. Хезмәтче малае белән бу кызны икесен бик зур туй ясап өйләндерәләр, хезмәтче малаен халык үзләренә патша итеп куя. Шул вакыттан алып хәзергәчә бу шәһәрдә халык бик тату, бик әйбәт яшиләр, ди.



МӨГЕЗЛЕ ПАТША

Борын заман бер патша була. Бу патша, чәчен-башын кырдыргач, чәч алучыларның башын кистерә торган була. Калада чәч алучылар бетә. Кала бер егет. Бу егетнең җитмеш яшьлек әнисе була. Патшаның чәчен-башын кырырга чират җитә моңа. Патша чакырта үзен. Егет, патшадан кире чыкмасын белеп, әнисе белән бәхилләшә.

— Үтерер инде мине дә, — ди.

Килә патша янына, чәчен-сакалын кыра. Шул вакыт патшаның мөгезен күрә. Патша шуңа күрә дә чәч алучыларның башын кистерә икән, халык белмәсен дип. Бу малайны патша кызгана. Моның да башын кистерсәм, чәч алырга бер кешем дә калмый, ди.

— Сине җибәрмим, ди, син минем мөгезне күрдең, халыкка сөйләрсең, — ди.

— Сөйләмәм, миндә андый акыл юк, — ди егет.

— Миңа сүз бир, ант ит, мин бу серне беркемгә дә сөйләмәм дип, — ди патша.

Малай ун куллап риза инде!

— Кемгә дә сөйләмәм, ант итәм, — ди.

Егет шулай дигәч, патша үтертми, әйтә:

— Һәр өч көндә минем янга сакалымны-башымны кырырга килерсең, — ди.

Бу кайтып китә өенә. Шуннан һәр өч көнгә патша янына килеп йөри, серне кемгә дә әйтми.

Беркөнне малайның анасы сорый:

— Нинди сер ул? — ди.

— Син сорама, мин әйтмим, мин патшага әйтмәскә сүз бирдем, — ди егет.

Малае шулай дигәч, әнисе сорамый инде. Шулай бер ай үтә, бер ел үтә, малайның эче зурая башлый. Малайның эчендә сер бар бит, ул аны кемгә дә сөйләми, ә сер һаман үсә, корсакны шештерә. Чирли бу малай. Әнисе сорый:

— Ни бар, ни булды, улым? — ди.

— Әни, үзем дә белмим, — ди бу.

Ахырда малай әйтә әнисенә:

— Эчемдә сер бар, кемгә дә сөйләргә ярамый, ә сөйләргә, бушанырга кирәк, юкса үләм мин, — ди.

Әнисе утырып елый да киңәш бирә улына.

— Бар син, ди, карурманга, кер урманның кеше йөрми торган бер җиренә, ди, куе гына урынга, ди. Казы шунда чокыр тирән генә иттереп, ди, төш шул чокыр төбенә, ди, шунда чокыр төбенә ят та өч мәртәбә сереңне әйт, — ди.

Икенче көнне малай ала көрәк, китә карурманга. Керә урманның эченә, куаклыкка. Кош та үтә алмый торган җир. Шунда тирән итеп чокыр казый. Казып бетергәч, төшә чокыр төбенә дә ятып өч мәртәбә кычкыра:

— Патшаның мөгезе бар! Патшаның мөгезе бар! Патшаның мөгезе бар! — дип.

Аннан чыга да чокырны күмеп куя, үзе китә. Бу киткәч, бу чокыр өстенә үсә өч камыш. Бик тиз үсә, зур булып. Ә малайның өенә кайтуга шеше бетә. Берникадәр вакытлар үткәч, бер

көтүче бу өч камышның берсен кисеп ала да курай ясый. Сызгырта башласа, курае кычкырта моның:

— Патшаның мөгезе бар! Патшаның мөгезе бар! — дип.

Бу көтүче һаман сызгырта, курае һаман шуны кычкыра. Бусын ташлый да икенче камышны кисеп ясый. Икенчесе дә шуны кычкыра. Хәзер камышның өченчесеннән ясап карый. Анысы да шуны ук кычкыра. Ҡитә бу көтүен куып, «Патшаның мөгезе бар!» дип кычкыртып. Урамнан кайтканда моны халык та ишетә.

— Бу ни хикмәт, бу ни тамаша? — диләр.

Бу хәбәр хәзер ишетелә патшага.

— Халык сөйләп йөри синең мөгезең бар дип, — диләр.

Патша уйлый: «Минем мөгеземне кем дә күрмәде. Күргән беренең башын кистердем. Сөйләсә сөйләгәндер теге егет», — ди. Чакырта бу егетне. Сорый:

— Я, мин сине үлемнән коткардым, ә син сүзеңдә тормадың, — ишетәмсең, халык ни сөйли, — ди.

Малай әйтә:

— И падишаһым-солтаным, мин кемгә дә синең мөгезең турында сөйләмәдем. Серемне үзем генә беләм. Ул хәбәрне каян ишеткәннәрдер, белмим, — ди.

— Ярар, тикшерербез, белербез, — ди патша.

Шуннан кем беренче килеп әйткән, шуны чакырта.

— Ҡаян ишеттең? — ди.

— Фәлән-фәлән кешедән, — ди теге. Патша ул кешене таптыра. Хәзер аңардан сорый:

— Ҡаян ишеттең син? — ди.

— Фәлән-фәлән кешедән, — ди бу да. Әйткән кешесен күрсәтә.

Шулай чакырта-чакырта көтүчегә җитәләр. Көтүче килә калтыранып, дерелдәп: «Нәрсә булыр икән?» — дип.

Көтүче килгәч, патша сорый көтүчедән:

— Ҡаян күрдең минем мөгезне? — ди.

— Гафу итегез, падишаһым, мин күрмәдем, — ди бу.

— Соң халык каян алып сөйли? — ди патша.

— Мин әйтмәдем аны, курай кычкырды шулай дип, — ди

көтүче. Шуннан курай турында сөйләп бирә. — Артык берни белмим, — ди.

— Кая кураең? — ди патша.

Көтүче курайны патшага бирә.

— Сызгыртып карагыз, ышанмасагыз, — ди.

Патша курайны ала да сызгыртып җибәрә. Курай:

— Патшаның мөгезе бар! — дип кычкыра.

Патша, ачуы килеп, курайны атып бәрә дә көтүчене куып чыгара. Инде егетне чакыртып сорый:

— Син беләсеңме, ни өчен болай булган? — ди.

Егет сөйли:

— Сезнең серне саклый-саклый эчем шеште, эчне бушатырга кирәк булды да карурманга барып шулай-шулай итеп әйттем мин, курай шул чокыр өстенә үскәндер алайса, — ди.

Патша уйлый-уйлый да бу егетне нишләтергә белми. Халык патшаның мөгезе барын белә бит инде.

— Бар, ычкын, күземә күренмә, — дип, патша бу егетне дә куып чыгара.

Ә халык көлә патшадан. Патша шулай итеп, хурлыкка чыдый алмыйча, кайгысыннан җүләрләнеп үлә. Аның урынына патша итеп чәч алучы егетне куялар.





БАКА, ТЫЧКАН, ЧАБАТА

Борын-борын заманда булган бер семья. Беркөнне атасы малаен чакыра да моңа унбиш тиен акча бирә.

— Бар кибеткә, алып кайт миңа шырпы белән тәмәке, — ди.

Китә малай кибеткә. Юлда барганда моңа туры килә бер тычкан.

— Әй малай, бир миңа биш тиен акча, — ди.

— Каян алыйм? — ди малай.

— Бир, зинһар, берәр кирәгеңә ярармын, — ди.

Малай уйлый да бирә моңа акчаны. Бераз китә. Моның каршысына сикерә-сикерә бака килә.

— Әй, бир миңа биш тиен акча, бер зур кирәгеңә ярармын, — ди.

Малай уйлый-уйлый да бирә. Тагы бара. Очрый моңа чабата. Бусы да биш тиен акча сорый. Малай, әтигә югалттым, дип

әйтермен дип, чабатага да биш тиен акчасын бирә. Бераз киткәч, борылып караса, өчесе бергә — тычкан да, бака да, чабата да моның артыннан киләләр, әйтәләр моңа:

— Син бик әйбәт малай икәнсең, сине юмартлыгың өчен буш итмибез, — диләр.— Бер патша бар, аның бик чибәр кызы бар. Кем дә кем аның кызын көлдерә алса, кызны шуңа бирә, диләр. Без сиңа алып бирәбез, — диләр.

Шулай дип, тычкан белән бака җигеләләр чабатага. Малайны утырталар да алып китәләр патша сараена. Малай кулында чыбыркы. И чаптыралар болар, и чаптыралар.

— Юлдан китегез! — дип малай кычкыруын гына белә.

Барып җитәләр болар патша сараена. Патша сараенын болдырында патша кызы белән патша үзе басып тора икән. Карыйлар болар. Патша кызы чабатага җигелгән тычкан белән бакага карый да чыдый алмый көләргә тотына. Эче катып көлә бу хәзер. Патша әйтә:

— Эһе, көлдең, хәзер үзеңне шул егеткә бирәбез, — ди.

Патша шулай дигәч, кыз да риза инде. Егетне алып керәләр патша сараена. Кияү булды бит хәзер. Ашыйлар, эчәләр. Ул арада кич тә була. Кыз бу егетне бик ярата башлый. Тик моның яратуын вәзир малае ошатмый. Вәзир малае кызны үзенә алмакчы булган икән. Әлеге егетне үтермәкче булып йөри. Беренче кичне теге малайны кыз белән үзләрен генә калдырмыйлар. Йокларга ята бу патша белән бер бүлмәдә. Шунда вәзир малае да керә. Йоклыйлар болар. Тычкан, бака, чабата сөйләшәләр: «Бу вәзир малае безнең егетне харап итмәкче була бит, әйдә без аның үзен кызык итик, — диләр. — Әйдә урлап бер борчак китерик», — диләр.

Китәләр борчак урларга. Тычкан берәүнең келәтенә кереп борчак урлап алып чыга, бака аны чабатага сала да кайтып та киләләр. Кайтып туп-туры патша бүлмәсенә керәләр. Бака борчакны вәзир малаеның борыны эченә сала, тычкан борын тишегенә койрыгын тыгып кытыклый башлый. Вәзир малае шул чак бик яман итеп төчкереп тә җибәрә, борчак очып барып патшаның маңгаена да тия. Патша куркып сикереп тора да:

— Кем эше бу? — дип кычкыра.

Вәзир малае, коты алынып:

— Мин идем, падишаһ хәзрәтләре, төчкергән идем, — ди.

— Син әле шулай мине мыскыл итәсеңме? — ди патша. Ялчыны чакырта да: — Менә бу юньсезне төрмәгә ябып куй, — ди.

Шулай итеп, вәзир малаен төрмәгә ябып куялар, чабатага утырып килгән егеткә зыян итүче булмый.

Икенче көнне туй ясыйлар. Патшаның туе була кырык көн, кырык төн. Туйны бик шәп итеп уздыралар да, малай кызны алып китәргә тиеш була инде. Җигәләр бик шәп атлар, арбаларга төйиләр маллар, байлык.

Тычкан, бака, чабата әйтәләр егеткә:

— Патша арбасына утырма, үземнеке бар дип әйт, — диләр.

— Безнең өй дә кыек бит әле, кыз белән нишләрбез икән? Кунаклар да күп булыр, — ди бу.

— Анысы синең эшең түгел, кайгырма, — диләр.

Малайны патша арбасына утыртмакчы булалар. Күпме әйтсәләр дә, утырмый. Кыз белән икәвесе чабатага утыралар. Кучер итеп алалар бер чикерткәне. Болар утыруга, бака белән тычкан бик яхшы айгыр булалар, чабаталары тарантаска әйләнә, ә чикерткә чибәр генә егет була. Патшаның да, аның якыннарының да исе китә бу эшкә. Туйны озата баралар. Малай кая барырга да, нишләргә дә белми, хур булырмын инде, ди. Кайта торгач, кайтып җитәләр. Атлар туктый зур бер сарай алдында. Капка төбендә егетне әтисе белән әнисе көтеп тора, ди. Шуннан болар тагы кырык көн, кырык төн туй итәләр.

Туйларында мин дә булдым. Куйдылар бер иләк катык. Карга кычкырды: «Карр!» дип, миңа ишетелде: «Пожар», дип, урамга чыктым, янабыз дип. Анда чыксам, бер ни юк.





ЭТНЕҢ БАШЫ ТАБАКТА ТОРМЫЙ

Бик борын заманда, мин дә булмаганда, син дә тормаганда, әбиләр дә яшәмәгәндә, торган-булган, ди, акыл иясе бер карт бабай. Бу бабайны һәркем яраткан, һәркем хөрмәт иткән, һәркем бу бабай кебек булырга тырышкан, ди.

Көннәрнең бер көнендә бу бабай янына бер бай килә дә:

— Я бабай, мине үзеңә эне ит, — ди.

Шунда бабай моңа каршы әйтә:

— Юк, улым, мин бай кеше белән агай-эне була алмыйм. Бай кеше үлгәнче малдан туймый, шуңа күрә син минем сүземне тота алмассың, — ди.

Бай әйтә:

— Юк, бабай, мин сүз бирәм, синең сүзеңнән беркайчан да чыкмам, — ди.

— Ярар алайса, без синең белән агай-энә булышабыз, тик минем әйткән сүзләремне үтәрсең, — ди бабай.

— Әйт, бабай, мин синең боерыгыңны үтәргә әзер, — ди теге бай.

— Алай булса, бар өеңә, — ди бабай. — Хатыныңнан, балаларыңнан аерыл, бөтен малыңны үзара тигез иттереп, дөрес

кенә бүл. Синең өлешкә төшкән малны көмеш акчага әйләндер дә аннан минем яныма килерсең, — ди.

Шуннан теге бай өенә кайта да карт-корыны җыя, мулланы китерә дә хатыны белән балаларыннан аерыла. Аннары бөтен малын, дәүләтен тигез иттереп бүлә дә үзенә төшкән өлешне акчага әйләндереп, акчаны бер капчыкка тутырып, теге бабай янына китә.

Байның бу эшенә бөтен халыкның исе китә. Кайберәүләр, мескен бай акылдан язды дип, кызганалар, кайберәүләр аңа шулай күптән кирәк иде дип сүгәләр. Дөньяда төрле халык бар бит, төрлесе төрлечә уйлый инде. Я, алар шулай сөйләсеннәр, без китик теге бай белән.

Бу бай, капчык белән акчасын җилкәсенә күтәреп, бабай янына килә дә:

— Я бабай, мин син әйткәннәрнең бөтенесен үтәдем, хәзер мин сиңа эне була аламмы инде? — ди.

— Юк әле, бу бөтенесе түгел әле, — ди бабай. — Менә хәзер синең бөтен акчаңны икебезгә тиененә кадәр тигез итеп урталай бүләбез, — ди.

Бай бераз уйлап торгач, моңарга да ризалашып, бер җиргә утыралар да бабай белән бөтен акчаны ике җиргә тигез иттереп бүләләр. Аннары бабай үз өлешен, бу бай үз өлешен җыеп алалар да бер агым су янына киләләр. Шунда бабай бу байга әйтә:

— Әйдә, син дә капчыгыңнан бөтен акчаңны суга сип, мин дә сибәм, — ди.

Бу бай, әй бу бабайны халык бик акыллы бабай дип белмичә әйтә икән, әгәр моның акылы булса, акчаны суга ташлатмас иде, дип уйлый. Шулай да, ни булса шул булыр инде ди дә, акчаны суга сибеп бетерә. Бабай да үз өлешен сибеп бетерә дә байга әйтә:

— Менә бусы әйбәт булды, ди. Инде хәзер икебез дә чишенәбез дә һәркем үзе сипкән акчаларны җыйсын, — ди. Бабай, шулай дип, суга кереп тә китә. Бу бай да өс-башын чишенеп суга акча җыярга чума.

Бай бервакыт су читенә чыкса, күзе белән ни күрсен, бабай да юк, киемнәре дә юк. Су чите дә таныш булмаган бер

җир булып чыга. Ерак түгел бер җирдә ниндидер бер ят авыл күренә. Бай шәрә көе су эченнән ярга чыга алмый. Шулай ни эшләргә белмичә торган вакытта бу күрә: шул авылдан ике кыз-хатын көянтә чиләк күтәреп моңа таба киләләр. Бу, оятыннан ни эшләргә дә белмичә, су эчендә генә тора. Бу хатыннар килеп, моны күргәч:

— Ни эшлисең, абый, монда? — дип сорыйлар.

Бай үзенең киемнәрен югалтуын әйтә. Шул вакыт суга килүче апалар әйтәләр моңа:

— Хәзер, абый, без сиңа киемнәр җибәрербез, — диләр.

Болар чиләкләренә су тутырып алып киткәч, озак та үтми, бер малай моңа киемнәр китерә. Бу бай киемнәрне киенә дә, оялып кына булса да, киемнәр китергән малай белән авылга китә. Бу авылда моны вакытлыча яшәргә бер өйгә урнаштыралар. Берничә көн яшәгәч, авыл халкы җыела да:

— Я дус кеше, сиңа болай йорт-җирсез яшәргә безнен җирдә дөрес түгел, үзеңә өй салырга, өйләнергә кирәк, — диләр.

Бай болардан бу сүзләрне ишеткәч, минем бу көнгә калганлыгымнан көләләр дип, боларга ачулана да:

— Минем йортлар салырга, өйләнергә акчам юклыгын бөтенегез бик яхшы беләсез, шулай да оялмыйча, алладан курыкмыйча көләсез, — ди.

— Юк, дус кеше, син ялгышасың. Безнең җирдә кешедән көлү дә юк, бездә бай-ярлы да юк. Без синең бернинди дә малың юк икәнен беләбез. Шуңа күрә без сиңа өй салабыз, үзең теләгән кызны хатынлыкка алып бирәбез. Шулай итеп, без сине үз арабызга алабыз, тик синең ризалыгың гына кирәк, — диләр.

Бу бай ризалык биргәч, моңа өч көн эчендә өй салып куялар, бер карт үзенең кызын да бирә. Шулай итеп бу бай бу авылда әйбәт кенә яши башлый.

Боларның эше: иртә торгач, кибеткә барып бер көнлек ризык алалар да шуны пешереп ашыйлар. Бу байның яңа хатыны моңа:

— Безнең илдә байлык җыярга ярамый. Кара, беркайчан

да бер көнлек ризыктан артык ризык ала күрмә, югыйсә харап булырбыз, — ди.

Бу бай берничә вакытлар шулай рәхәт кенә яши, эшкә дә теләсә бара, теләмәсә юк. Тамагына да нәрсә теләсә шуны ашый, өстенә дә ни теләсә шуны кия — беркем бер сүз әйтми.

Шулай яхшы гына яшәгәндә, бу бай беркөнне уйлый: «Мин бит бай идем. Мондый халык миндә кол булып эшли иде. Ә мин аларга кычкыра идем, сүгә идем. Мин алардан олы идем, миңа дөньяда яшәве рәхәт иде. Ә монда бөтен халык бер хокукта, кем каршында горурланырга да юк, ди. Бу хатыннарның сүзен тыңлап тору ярамый, аларның чәче озын, акылы кыска. Мин әкрен-әкрен генә мал җыйыйм да, шулай итеп баермын, малым күп булыр. Шуннан соң бу җирдә дә мин хуҗа булырмын», — ди. Бай, шулай дип, мал җыярга керешә. Хатыны, иренең бу эшен сизгәч, әйтә:

— Әй, карт, безнең илдә мал җыярга ярамый, җыйма, югыйсә харап булабыз, — ди.

Хатыны күп сөйли, ире аз ишетә, мал җыюын дәвам итә. Шулай көннәрнең бер көнендә бу бай җәй эссесендә елгага су керергә китә. Су читендә өстен чишенә дә суга чума.

Судан чыкса, күзе белән ни күрсен, су читендә элгәреге, бай вакытындагы киемнәре ята. Ерак та түгел үз туган авылы күренә. Бу бай бу эшкә хәйран калып торган арада, теге бабай килеп чыга да:

— Я, улым, синең күзең дөнья малыннан туймый, тамагың кеше каныннан туймый, ә кул-аягың кеше җәберләүдән туймый икән. Шуңа күрә син минем белән агай-эне була алмыйсың. Мин үз кул көчем белән дөньяда яшим, кеше канын эчмим, байлык җыймыйм. Мә, бөтен акчаң исән-сау, бер тиенен нә кадәр төгәл. Сиңа тагы ни кирәк иде? Өең юк иде, өй салып бирделәр, хатының юк иде, үз кызымны биргән идем. Күңелең нәрсә теләсә шуны ашый-эчә идең, эшне дә теләгән чаклы, теләгән вакытта эшли идең. Бүрене күпме генә халык арасында асрасаң да, ул урманга кача, үзенең ерткычлыгын онытмый, диләр. Бар да бик дөрес, — ди. Шулай ди дә бабай үз юлына китә.



АЛТЫН АЛМАЛАР

Яшәгәннәр, ди, ике күрше: берсе — бик бай, берсе — бик ярлы. Бай күршеләре кичке ашны ашап, чәй эчәләр дә икән, ирле-хатынлы тыныч кына, тавышсыз гына яталар икән йокларга. Ә теге ярлы кешеләрнең балалары күп булган, шуңа күрә боларда гел тавыш-гауга, җырлау-җылау, бию-көлү тавышлары яңгырап торган. Бу эшкә теге байның исе киткән. Үз-үзенә: «Боларның ашарларына юк, киярләренә юк, алай да гомерләрен шат үткәрәләр, — ди икән. — Ә безнең шулкадәр байлыгыбыз күп, алай да без шат яшәмибез», — ди икән.

Беркөн бу бай ярлы күршесеннән:

— Сез ничек шулай шат яшисез? — дип сорый.

Теге ярлы моңа әйтә:

— Безнең җиде алтын алмабыз бар, без шулар белән уйныйбыз, — ди.

Шуннан бу бай егерме алтын алма ясатып кайта да:

— Хәзер без дә шат яшәрбез, — ди хатынына.

Моның хатыны бер почмакка, үзе икенче почмакка утыралар да алтын алмаларны бер-берсенә тәгәрәтеп уйныйлар. Беренче вакытта кызык кебек була. Бераздан бернинди дә кызыгын тапмыйлар, уенны ташлыйлар. Шуннан соң бай ярлыга үзенең ничек уйнаганын сөйләп бирә. Ярлы моңа әйтә:

— Мин сиңа андый алмалар турында әйтмәдем. Әгәр ул алмаларны күрәсегез килсә, кич белән безгә керегез, — ди. Кич булгач, бай хатыны белән боларга керә. Керсә, бу ярлының җиде баласы кайсы бии, кайсы җырлый, кайсылары үзара сугыша, кайсылары төрле уеннар чыгара. Бу байларның да балаларга карап күңелләре ачыла. Шуннан бу бай ярлыга:

— Синең байлык минем байлыктан күбрәк икән, — ди.



АЛТЫН ТӘМӘКЕ САВЫТЫ

Бервакытта бер егет бер авылдан икенче авылга бара. Җәяү бара бу. Бара торгач, арый да бер төштә җиргә утырып ял итә. Шул чакны егетнең кесәсеннән җиргә алтын тәмәке савыты төшә. Савытның тышына фәрештәсыман бер сурәт төшерелгән була. Егет озак утырмый, торып үз юлына китә. Шул җирдән ерак та түгел бер көтүче сыерлар көтеп йөри. Йөри торгач, әлеге егет утырган җиргә килеп чыга. Карый бу, җирдә нидер ялт-йолт ялтырый. Әйбәтләп бакса, җирдә фәрештә сурәте ята. Шунда әйтә көтүче:

— Бу фәрештә алладан килгәндер, тизрәк мулланы чакырырга кирәк, — ди.

Савытны бүреге белән каплый да, көтүен ташлап, авылга чаба. Авылга кайтып җиткәч:

— Әй җәмәгать, тизрәк җыелыгыз, кырыбызга фәрештә төшкән, нидер сөйли, — ди.

Чакыра бу муллано, мәзинне. Халык җыелып беткәч, китәләр теге савыт яткан җиргә.

Ә бу юлчы егет бераз киткәч тә кулын кесәсенә тыгып карый, караса, тәмәке савыты юк. Шуннан моның исенә төшә дә кире килә утырган җиренә. Килеп караса, савытны бүрек белән каплап куйганнар.

— Тукта, монда ни булса да бар, — ди.

Савытны ала да бүреге белән якындагы сыер тизәген каплап куя, үзе кырыйга китеп яшеренә.

Бервакыт авылдан халык килә дөнья кубарып. Алдан чаба көтүче, аның артыннан мулла белән мәзин. Көтүче китерә боларны туп-туры бүрек янына.

— Менә бүркем астында, — ди. — Фәрештәне кем алырга тиеш хәзер? — ди.

Халык әйтә:

— Әйдә, хәзрәт, син алырга тиеш ходай йомышчысын, — ди. Мулла риза. Иң башта ятып, колагын куеп тыңлап карый да:

— Бисмиллаһи рахмани рахим... — дип кулын бүрек астына тыга, тыга да анда ни барын сизеп кулын кире ала. Кулы пычрана моның, алай да халыкка белгертми. Әйтә мәзингә:

— Миңа килми, син алып кара, мәзин, — ди.

— Мәзин дә бисмилласын әйтеп кулын тыга, аңа да фәрештә килми. Кулы пычранганын бу да сиздерми.

— Миңа да килми нишләптер, — ди.

Инде кем алсын? Халык әйтә:

— Әйдә, көтүче, булмаса, үзең ал, — ди.

Көтүче бүрек астына тыгыла, тыгылса, тегендә тизәк. Бу хәлне күргәч, көтүче мулланы сүккән, ди.



8 тиен

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1963

